# Низаметдинова Миләүшә Илдар кызы



Березняк урта гомуми белем бирү мәктәбендә

1994 нче елдан эшлим.

Педагогик эш стажым – 22 ел.

2001 нче елдан мәктәптә татар теле һәм әдәбияты

дәресләре алып барам.

Укытучы буларак тормыш девизым-

Укучылар өчен һәр дәрес ачыш, һәр дәрес могҗиза булырга тиеш!

# Мәктәп еллары





Укытучы... Мәктәп... Кечкенәдән укытучы булу хыялы белән яшәү мине Арча педагогия училищесына алып килде



Гыйлем эзләп
килгәнгә дә
Синдә җылы
табылган-
Мәгърифәтле
кочагында
Күпме акыл
кабынган

Студент еллары артта калды...
Кайчандыр үзем укыган мәктәпкә

эшкә кайттым.





*Яраткан хезмәтемнән тәм табып, балаларга индивидуаль якын килеп эшләргә тырышам.*





# Татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак үз алдыма куйган максатларым

- *Туган телгә мәхәббәт тәрбияләү*
- *Халкыбызның үткәне белән кызыксыну булдыру*
- *Кешелеклелек, миһербанлык, әхлак сыйфатлары тәрбияләү*
- *Әдәбият фәне белән кызыксыну булдыру*
- *Орфографик күнекмәләр формалаштыру*
- *Фонетика, лексика, морфология, синтаксис тармакларын тирәнтен өйрәтү*
- *Бәйләнешле сөйләм төзү күнекмәләре булдыру*

# Үземнең эш практикамда түбәндәге эш алымнарына игътибар итәм

- Төрле дәрес формалары куллану
- Проблемалы укыту технологиясен файдалану
- Яңа информацион технологияләр куллану
- Белемнәр тикшергәндә тест формаларын куллану
- Укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү өстендә эшләү
- Сәләтле укучылар белән индивидуаль эшләү

# СӘЛӘТЛЕ УКУЧЫЛАР БЕЛӘН ЭШЛӘҮНЕ СИСТЕМАЛЫ РӘВЕШТӘ АЛЫП БАРАМ



# Укытучы хезмәте авыр да, шул ук вакытта кызыклы да...




Күзләреңдә бүген
борчу түгел,
Шатлык яна синең
җиңүдән.
Алда ята дәрес
планнары,
Дәфтәрләре янда
өелгән.

*Үземнең эш тәҗрибәм белән дә теләп уртаклашам: педсоветта, методик семинарларда, ата-аналар алдында чыгышлар ясыйм.*





## ***Соңгы елларда түбәндәге темаларга чыгышлар ясадым:***

- “Әдәпле булу- бәхетле булу”
- “Укучыларга эстетик тәрбия бирү”
- “Мәктәп балаларына экологик тәрбия бирү”
- “21 нче гасыр башында сыйныф җитәкчесенең тәрбиялелек эшчәнлеге”
- “Милли төбәк компонентларын укытуда куллану”
- “Балаларның физик һәм рухи сәламәтлеге”
- “Укытуда яңа технологик алымнар куллану”

# Сыйныф җитәкчесе буларак эшчәнлегем



Сыйныф җитәкчесе буларак эш стажым -14 ел. Бүгенге көндә 9 нчы сыйныфның җитәкчесе

## *Көзге бал, Яңа ел бәйрәмнәренә укучылар белән бергәләп әзерләнәбез*






Әти- әниләр белән даими элемтәдә торам.Аларны ачык дәресләргә чакырам, бәйрәм кичәләрендә әти- әниләр көтеп алынган кунакларыбыз.







# Сәламәт тәндә - сәламәт акыл





**9 нчы сыйныфта – 4 укучы. Укучыларның 3се спорт түгәрәкләренә йөри. Мәктәп күләмендә үткәрелгән спорт ярышларында, класстан тыш чараларда актив катнашалар.**

# *Район конкурсларында катнашучы укучыларның берничәсе*





# Укучыларның эш нәтиҗәләре



***“Һәрбер кеше үз кулыннан килгән кадәр эш эшләргә, байлык вә һөнәр һәм дә сәнгать өлкәсендә милләтнең күтәрелүенә ярдәм кылырга тиеш. Халкының үткәнен, тарихын, сәнгатен өйрәнгән, хезмәт сөйгән, матурлыкны күрә белгән, үзара дус һәм тату мөнәсәбәттә тәрбияләнгән балаларның киләчәге өметле.”***

Ризаэтдин Фәхретдин

# Барыгызга да саулык –сәламәтлек , бәхет-шатлык телим!



Сабыр холык,
Тыйнак акыл белән,
Саклап Телне,
Сакла безне,
Татар теле
Мөгаллиме!